СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**«29» май 2020 ел** **№49**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

“Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге уставын гамәлдәге законнарга яраклаштыру максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына таянып, Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 27 октябрь 2014 ел, №13 карары белән расланган Ташкичү авыл җирлеге уставына (26.10.2015 №7.1, 01.11.2016 №29, 11.05.2017 №3, 08.05.2018 №6, 07.09.2018 №9, 09.10.2019 №37 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

**1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 20 пункт өстәргә:**

20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү, үзбелдекле төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү»;

**2) 30 статьяның 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«9. “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил

финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясының 7_2 нче өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) җирле үзидарә депутатының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә депутатка карата башка җаваплылык чарасы куллану турында тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка гариза белән мөрәҗәгать итә»;

**3) 30 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 9.1 пункты өстәргә:**

«9.1. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган мәгълүмат биргән җирле үзидарә депутатына карата, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү артык әһәмиятле булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вәкаләтләр биләү хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләре срогы тәмамланганчы вазыйфасыннан азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, вәкаләтләре срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфалар биләүне вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю;

5) даими нигездә вәкаләтләрен үтәүн вәкаләтләре срогы тәмамланганчы тыю»;

**4) 30 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 9.2 пункты өстәргә:**

«9.2. Җирле үзидарә депутатына "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7_3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.».

**5) 85 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

« 85. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләр, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлары,

шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, башлангыч һәм чираттагы төрләргә бүленә.

2. Тышкы муниципаль финанс контроле-Җирлекнең Ревизия комиссиясенең контрольлек итү эшчәнлеге.

3. Эчке муниципаль финанс контроле-Җирлек башкарма комитеты органнары (вазыйфаи затлары) булган муниципаль финанс контроле органнарының контрольлек итү эшчәнлеге.

4. Башлангыч финанс контроле Җирлекнең җирле бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Чираттагы финанс контроле Җирлек бюджетының үтәлеше нәтиҗәләре буенча аларның үтәлешенең законлылыгын, исәп-хисапның дөреслеген билгеләү максатыннан башкарыла.».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә башкарма хакимиятнең уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгына "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны башкарма хакимиятнең уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль органының территориаль органыннан кергәннән соң 7 көн эчендә гражданнарның күпләп җыелу урыннарында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгына рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн эчендә башкарма хакимиятнең уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә вәкаләтле федераль органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү чыганагы һәм датасы турында белешмәләр җибәрергә.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ Ф.Х.Фәйзуллин